ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты,
Россия, 421111, Казан ш., К. Маркс ур., 12/4 нче йорт,
Alfat_zak@mail.ru.

Хезмәттә танылган татар галиме, шагыйрь, драматург, фольклорчы, тәрҗемәче, публицист Нәкый Исәнбәтнең татар драматургиясе үсешенә керткән өлешен бәяләү омтылышы ясала. Күпкырлы эшчәнлек алып барган Н. Исәнбәт драматургиягә XX гасырның 10 нчы елларында килә һәм 70 нче елларга кадәр актив иҗатта була. Аның каләменнән төшкән утыздан артык пьесаның барысы да диярлек үз вакытында сәхнәләштерелә. Әдип пьесаларында чорның мөһим вакыйгаларын, тарихның гыйбрәтле сәхифәләрен чагылдыра, шуңа да алар татар халкы тарихының әдәби елъязмасы буларак кабул ителә. Хезмәттә Н. Исәнбәтнең иҗади үсеш-үзгәреш этаплары һәм аларның үзенчәлекләре билгеләнә. Әдип, драматург буларак, 1920 нче елларда танылу ала. Бу вакытларда язылган пьесаларында, инкыйлаблар чорында адашып калган элекке байлар һәм руханилар тормышын көлеп сурәтләү белән бергә, яңа җәмгыять шартларында мәйданга килгән бюрократлык, күзбуяучылык кебек күренешләрне фаш итә. Алдагы чорда Н. Исәнбәт иҗатында кискен борылыш күзәтелеп, ул тарихи шәхесләрнең әдәби образларына һәм халык авыз иҗатында тупланган бай мираска мөрәҗәгать итә. Иҗат гомерендә шуларга тугры калган хәлдә, язучы җәмгыятьтәге мөһим мәсьәләләрне укучы-тамашачы алдына куя, чорның гыйбрәтле типларын мәйданга чыгара һәм пьесалары театрлар репертуарында лаеклы урын ала. Шул рәвешле «Нәкый Исәнбәт театры»н булдыруга ирешә. Дистәләгән пьесасының хәзерге татар театрларында уйналып килүе әдип әсәрләренең заманчалыгы, тарих сынавын уңышлы үтүе турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

**Төп төшенчәләр**: татар драматургиясе, Нәкый Исәнбәт, иҗат этаплары, әдәби процесс, традицияләр һәм яңачалык, чор тибы, конфликт үзенчәлеге

**Сылтама өчен:** Закирҗанов Ә.М. Нәкый Исәнбәт һәм татар драматургиясе // Tatarica. 2025. № 1 (24). 34–48 б. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-24-1-34-48

## Кереш

Н. Исәнбәт татар мәдәниятенең фольклор, поэзия, драматургия, тел, публицистика, тәнкыйть кебек өлкәләрендә хезмәт куеп, һәркайсында зур казанышларга ирешә һәм бай мирас калдыра. Ә инде татар сәхнә әдәбиятында җитди сыйфат үзгәрешләренә, жанр өлкәсендәге эзләнүләргә, сәнгати табышларга китергән әсәрләре белән үзгә урын алып тора. Иҗат юлында язылган утыздан артык пьесасының барысы да диярлек сәхнәләштерелүе, спектакль буларак яңгыраш

алуы һәм иң уңышлыларының татар театрларында даими куелып килүе – язучы иҗатына бирелгән иң зур бәя чагылышы.

Н. Исәнбәт ил-халык тормышының гаять катлаулы, каршылыклы чорлары эчендә кайнап, шуларны үз иҗатында чагылдыра. Аның шигырь-поэмалары, бигрәк тә драмалары чын мәгънәсендә халык тарихының әдәби елъязмасы булып тора. Татар халык мәкаль-әйтемнәрен, мәзәк-табышмакларын җыю, аңлатмалы һәм фразеологик сүзлекләр төзү, мифлар, ырымнар, им-томнар һәм дастаннарны туплау, әдәби эшкәртү, бәяләү кебек эшчәнлеге белән үзен «халык рухының, халык иҗатының энҗеләрен, такыя кебек үреп, килер буыннарга тапшырган зат» [1, 294 б.] итеп таныта. Фәнни эшчәнлекне әдәби иҗат белән чиратлаштырып алып барган Н. Исәнбәт драматургиясе тема һәм жанр өлкәсендәге эзләнүләре, чор мәсьәләләрен үзгә позициядән чагылдыруы, үткән тарих һәм дәвер куйган сорауларга актив җавап эзләве, эчтәлек һәм формада яңа алымнарга, яңа сурәтләргә омтылуы белән аерылып тора. Мәкаләдә чор әдәби процессына нисбәтле әдипнең драматургиясенә күзәтү ясау, аларда традицияләр дәвамчанлыгын һәм яңалыкларны билгеләү, сәхнә әдәбияты тарихындагы урынын ачыклау максат булып тора. Хезмәтнең фәнни яңалыгы, теге яисә бу әдәби чор үзенчәлекләренә бәйле, язучы пьесаларында күзәтелгән табышларны, аларның әдәби барышка йогынтысын ачыклау, шулар аша гомумиләштереп нәтиҗәләр ясау һәм драматургия тарихындагы урынын билгеләү омтылышы белән аңлатыла.

## Тикшеренү методлары

Тикшеренүнең методологик нигезе булып герменевтика, ягъни әдәби текстларны шәрехләү аша эчке сыйфат-билгеләрен, тарихи-функциональ һәм эстетик анализ ярдәмендә авторның әдәби фикерләү үзенчәлеген ачыклау тора. Төп максатка нисбәтле чагыштырма-тарихи һәм системалы методлардан файдалану аша төрле чорда язылган әсәрләр үсеш-үзгәрештә бәяләнә һәм система буларак нәтиҗә ясала.

## Фикер алышу

Н. Исәнбәт драма әсәрләрен XX гасырның 10 елларында ук яза башлый («Урнаш», 1912; «Әмирхан хәзрәт», 1916) һәм, өзеклекләр белән, 70 елларга кадәр («Кырлай егете» (1968), «Хәйләкәр Дәлилә, яки “Мең дә бер кичә”дән бер кичә» (1978)) дәвам итә. Әдипнең әсәрләре, аеруча спектакльләре үз вакытында ук игътибар үзәгендә була, матбугатта алар турында даими күзәтүләр чыгып килә. Бер төр хезмәтләрдә пьесаларының идея-эстетик үзенчәлеге, образ-характерлары, сәнгати алымнары тикшерелә (А. Әхмәдуллин [2], [3], [4], Р. Рахмани, Ф. Миңнуллина [5], Ф. Миңнуллина [6], Н. Ханзафаров [7]), икенчеләрендә әдип пьесалары буенча куелган спектакльләргә рецензияләр, аларның сәхнә тарихы, театр сәнгатен үстерүдәге роле билгеләнә (Г. Арсланов [8], [9], Р. Җамалетдинов, М. Хәбетдинова [10], Г. Шамуков [11], А. Хәбетдинов, М. Хәбетдинова [12], М. Хәбетдинова [13], [14], [15], [16] өченче төр хезмәтләрдә Н. Исәнбәтнең шәхесенә, күпкырлы эшчәнлегенә, шул исәптән драматург буларак та күзәтү ясала (Р. Батулла [17], [18] М. Госманов [19], Ә. Еники [20], М. Хәбетдинова [21], [22] Б. Урманче [1], Р. Фәйзуллин [23] һ. б.).

Әдипнең сәхнә әдәбиятына караган бай мирасын өйрәнү, сәнгати фикерләү үзенчәлекләрен киң катлам укучыларга җиткерү буенча зур эш башкарыла. Замандашы Ә. Еники аның драматургиясенә мондый бәя бирә: «Нәкъ сәхнә таләп иткәнчә, эчке интонациягә бай, үткер сөйләм теле, индивидуаль характерларга ия чын кеше образлары. Оста һәм тыгыз үрелгән конфликт – менә аның әсәрләренә хас сыйфатлар» [20, 5 б.]. Н. Ханзафаров «Нәкый Исәнбәт драматургиясе» дип аталган махсус тикшеренүендә һәм шуның буенча әзерләнгән монографиядә [7] әдипнең тормыш һәм иҗат юлына күзәтү ясап, сәхнә әдәбиятына килү юлын һәм пьесаларын жанр табигатенә, конфликт үзенчәлегенә һәм геройлар бирелешенә нисбәтле эзлекле системада тикшерә. Н. Исәнбәт әсәрләренең сәхнә тарихы аеруча тулы рәвештә Г. Арсланов хезмәтләрендә чагылыш таба [8], [9]. Аларның кыйммәте шунда: автор әлеге спектакльләрне шул чор мәдәни мохитендә һәм режиссерларның, артистларның сәнгати эзләнүләре, яклаган концепцияләренә нисбәтле бәяли. Соңгы елларда Н. Исәнбәт шәхесен һәм күпкырлы эшчәнлеген өйрәнү буенча аеруча зур хезмәт М. Хәбетдинова тарафыннан башкарыла [13], [14]; [15], [16], [21], [22]. Аның күпсанлы мәкаләләрендә әдип шәхес һәм иҗатчы буларак ачыла, пьесаларының үз вакыты һәм бүгенгебез өчен әһәмияте

билгеләнә, татар әдәбияты һәм театры тарихындагы урыны, шулай ук әдәби образын тудыру омтылышлары билгеләнә.

Н. Исәнбәтнең күпкырлы фәнни һәм әдәби мирасы уртак һәм бөтенлекле концепциягә нигезләнә. Ул – туган халкы мәнфәгатенә хезмәт итү. Исәнбәт малай вакытта ук әйләнә-тирәдәгеләрне, гаилә әгъзаларын, дусларын, авылдашларын мәгърифәтле итү, аң-белемгә, әдәп-әхлакка тарту теләге белән янып яши. Ул гомере буе чын мәгънәсендә мәгърифәтче булып кала. Журналист Ф. Зөлкәрнәев белән әңгәмәсеннән күренгәнчә, бу төшенчәне уку-укытуга гына кайтарып калдырмый, бәлки киң мәгънәсендә халыкка хезмәт итү белән бәйләп карый: «Мәгърифәтчелекнең төп максатларыннан берсе – халыкның меңнәрчә еллар буе иҗат иткән, туплаган культура казанышларын, күңел хәзинәсен үзләштерүдә бүгенге кешеләргә ярдәм итү. Болай уйлап караганда, минем барлык хезмәтләремне дә берләштерә торган төп идея, мөгаен, шушы фикергә кайтып каладыр» [24, 710–714 б.].

Нәкый әдәбият белән бик иртә кызыксына башлап, беренче шигырьләрен 10 яшьтә иҗат итә, 11–12 яшендә «Балта», «Балга», бераз соңрак «Күсәк» исемле кулдан эшләнгән журналлар язып чыгара. Нәкый аганың «Минем язучы булуым һәм халык иҗаты өйрәнүем» [24, б. 109–114 б.], «Шигырь чыгаруым юлында минем кайбер эзләнүләрем турында» [24, 114–118 б.] һәм «Мин ничек шагыйрь булдым» [24, 282–301 б.] исемле кульязмаларында әдәби иҗатка килү, моңа китергән сәбәпләр, йогынты ясаган кешеләр, шәхси кызыксынулары, әдәби иҗат серләре һ.б. турындагы фикерләре яшь буынга бер үрнәк, тәҗрибә булып тора. Аның әлеге кызыксынуларына, табигый талантыннан тыш, әнисе, Шәмсенур апасы, ул яшәгән шаулы чор, әйләнә-тирә мохит һәм Уфадагы «Хөсәения», Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә укуы зур йогынты ясый. «Тәрҗемәи хәлем язмасында болай дип яза: «1914 елда мин Казанга «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә килдем һәм ике ел анда укыдым. Дөресен әйткәндә, уку өчен түгел, Казанга шагыйрь булып әсәр бастыра башларга килдем» [24, 28–29]. Әйтергә кирәк, ул максатына ирешә дә, аның шигырьләре «Ак юл», «Сөембикә», «Аң» журналларында басылып чыга, исеме әдәби җәмәгатьчелек теленә керә.

Аның шигърияте шактый зур булып, дөньяга карашын, күңелендәге хис-кичереш, уй-фикер байлыгын чагылдыра, хәтта әдипнең төрле чорлардагы күңел-җан хәрәкәтен дә тоемларга мөмкин. Нәкыйнең беренче шигырьләрендә үк яшәешнең җитди мәсьәләләре турында зурларча фикер йөртүче лирик герой белән очрашабыз, шигъриятендә шул чорда зур кызыксыну уяткан тема-мотивлар белән очрашабыз: табигать-пейзаж, уку-белем, социаль тигезсезлек, яшәеш каршылыклары, әдәп-әхлак һ.б. Аның бер яктан фольклорга нигезләнгән, икенче яктан шәрык, шул исәптән төрки язма әдәбиятына таянган шигырьләре шул чор татар әдәбияты барышына кушылып китә. Билгеле, тәҗрибә арта барган саен, шагыйрьнең илдәге катлаулы тарихи-сәяси, иҗтимагый, мәдәни, милли һ.б. мәсьәләләрне аңлавы, сәнгати чагылдыру осталыгы да үсә бара. Бу аеруча сугышка нәфрәт чагылу, афористик яңгыраш, гыйбарә булып китәрдәй фикерләр, хис-кичерешкә бай сурәтлелекнең кайнар публицистик рух белән сугарылуы кебек билгеләрдә чагылыш таба. Ул аерым тема-мотивларга әледән-әле әйләнеп кайта, алар еш кына тотрыклы лейтмотив төсен ала.

Шулай да киң катлау укучылар арасында Н. Исәнбәт лирик шигырьләре белән танылу ала. Аларның музыкальлеге, романтик рухы, купшы сурәтлелеге көйгә салынуны сорый, нәтиҗәдә, көй-моң белән кушылып, популяр җырлар («Уракчы кыз», «Бормалы су», «Син сазыңны уйнадың», «Туган ил» һ.б.) булып китә. Әлеге шигырьләрнең үз вакытында һәм бүген дә заманча яңгырашы шул чорның кайнар рухын, ашкынулы яшәү ритмын, матур омтылышларны чагылдырулары һәм әдипнең теле, бай сурәт чаралары, халык авыз иҗаты әсәрләреннән килеп кергән бизәклелек, аһәңлек, җорлык белән аңлатыла *(«Моңланып ай нурларында, / Син сазыңны уйнадың»).* Әдәби таланты, вакыйга-күренешләрне эпик сурәтләү омтылышы Н. Исәнбәтне поэма жанрына китерә. 1917 ел инкыйлабларына кадәр «Качкын», «Укытучы кыз», «Сукбай» кебек әсәрләре языла, ә инде 1920-30 елларда «Эшче Хафиз» (1929), «Контрабандистлар» (1931), «Днепрострой» (1933) һ.б. поэмалары дөнья күрә. Сугыштан соңгы елларда аерым уй-фикерләре, хис-кичерешләренә бәйле поэмалар («Нужа бабай» (1949)) языла. Алар ил-халык тормышының тарихи-поэтик елъязмасы рәвешендә кабул ителә. Аның шагыйрьлеге драматик поэмалар, ягъни тезмә белән язылган

пьесаларны («Түләк» (1942), «Әбүгалисина» (1958)) мәйданга чыгара.

***

Н. Исәнбәт драматургиясе, берничә чор-этап аша үтеп, сәхнә әдәбиятында яңа әдәби дөнья сурәте тудыру омтылышы белән аерылып тора. 1917 елгы инкыйлабларга кадәр ук бу өлкәдә тәҗрибәләр ясап караса да, драматург буларак 1923 елда язылган «Һиҗрәт» комедиясе белән танылa [4, б. 176]. 1920 елларның I яртысында иске тормышны кире кагу, аның караңгылыгын, хезмәт ияләренең михнәтле тормышын күрсәтү яисә бәреп төшерелгән элекке югары катлау кешеләрен кара һәм көлкеле төсләрдә чагылдыру өстенлек итә. Казанда К. Тинчуринның «Җилкәнсезләр» (1923), шулай ук «Сүнгән йолдызлар» (1923), «Зәңгәр шәл» (1926) кебек пьесалары уңыш белән куела. Бу чорларда язылган байтак әсәрләр кебек, «Һиҗрәт»не дә төрлечә аңлау һәм бәяләү мөмкинлеге бар. Билгеле, авторның инкыйлаб шартларында адашып, кемне якларга белмичә икеләнеп калган элекке байларга, руханиларга карашы бертөрле генә түгел. Асылда аларны комедиячел типлар итеп сурәтләсә дә, җирен, байлыгын югалткан, киләчәген күз алдына китерә алмаучыларны аңларга да омтыла. Гомере буе иманлы яшәп, хәзер Аллаһны оныттыруны ничек бәяләргә? Шуңа да пьесаны һәм аның буенча куелган спектакльләрне бәяләүдә фикер төрлелеге дәвам итә. А. Әхмәдуллин пьесаны төрлечә кабул итүгә урын калдырып, Н. Исәнбәт инкыйлаб нәтиҗәләреннән «үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртучылар, ялагайлар, койрыксыз-җилкәнсезләр, комсызлар»га (...) «карата укучы һәм тамашачы күңелендә нәфрәт тәрбияли» [4, б. 177], дип яза. А. Хәбетдинов һәм М. Хәбетдинова исә «Һиҗрәт» пьесасында билгеле тарихи шәхесләр образлары чагылыш таба, дигән караштa тора. Авторлар пьеса буенча Әлмәт театрында И. Зәйниев куйган спектакльдә «тарихи вакыйгаларның тирән эчтәлеге» [12, 118 б.] читтә калуын билгелиләр. Гомумән, инкыйлаблар һәм гражданнар сугышына бәйле татар җәмгыятендәге каршылыклар чагылыш тапкан әсәрне бәяләү һәм театр сәхнәсе аша халыкка җиткерүдә җитди бурычлар кала.

1923 елдан Н. Исәнбәт Уфада яши, мулла улы буларак аңа кырын карау, еш кына «юлаучы» дип атау шартларында язучы буларак танылa алуның авырлыгын күз алдына китерү кыен түгел. Әдәбиятта киләчәкне ал төсләргә манып сурәтләү кебек мифлар киң колач җәя. «Яңа икътисади сәясәт» (НЭП) һәртөр бушкуык һәм шарлатанга үзен күрсәтү, хөкүмәт карарларыннан файдаланып, баеп калу, дәрәҗәле эшкә урнашу мөмкинлеге бирә. Ул исә еш кына бюрократлык, эш урыныннан, биләгән вазифадан файдалану һ.б. күренешләрнең чәчәк атуына китерә һәм хаклы рәвештә ризасызлык уята. Шундый шартларда әдәбиятның алдынгы көчләре яшәештәге җитди кимчелекләрне фаш итү, аларны көлеп сурәтләүгә килә. «Культур Шәнгәрәй» (1927), «Пикүләй Шәрәфи» (1929), «Портфель» (1929) кебек сатирик комедияләре белән Н. Исәнбәт яңа башлангычка нигез сала: халыкчан көлү традициясен алга чыгарып иҗат итә башлый. Бу исә сурәтләнгән вакыйга-күренештән усал көлүне һәм кисәтү рәвешендәге фаш итүне күздә тота. Җитди яңалык буларак, хронотоп бөтенлеге аша, яңа, тагын да тирәнрәк мәгънәне ачуга киленә. Авангард форма рәвешендә көлкеле яисә мәгънәсез хәл-күренеш сюжет төзүдә башлангыч, этәрелеп китү нигезе буларак урын ала. Әлеге билгеләр югарыда аталган пьесаларның бүген дә сәхнәгә куелышын, һәр заман өчен актуаль булуын тәэмин итә.

Әлеге әсәрләрнең сәхнә язмышы җиңелдән булмый. Вульгар социологизм тарафдарлары һәр сүздән, репликадан, образдан ниндидер үзгә мәгънә эзләү белән мавыгалар. Н. Исәнбәт комедияләренә карата совет җәмгыятен каралтып күрсәтә, ә социалистик җиңүләрне күрми, дигән берьяклы тәнкыйть сүзләре яңгырый [2, 206–207 б.]. Әлеге һәм башка сәбәпләргә бәйле рәвештә, Н. Исәнбәт 1930 елны Казанга күчеп килә. Әмма ул ныклап урнашырга да өлгерми, «Җидегән» милләтчеләр оешмасына керүдә гаепләнеп, эзәрлекләүләргә дучар була, 1931 елны ике ай төрмәдә утырып чыга. Ул чорда «җидегәнчеләр»гә каршы оештырылган шау-шу, җәнҗалны күз алдына китерүе авыр. Әдип бер истәлегендә ТАПП (Татарская ассоциация пролетарских писателей) әгъзаларының «җидегәнче» дип аны әдәби процесстан читләштерүләре турында яза. Башка эш таба алмагач, «Спартак» фабрикасына урам җыештыручы булып урнаша. Бер төркем язучы шунда да тынычлыкта калдырмыйча, фабрикага килеп, гомуми җыелышта аны һәм башка «җидегәнчеләр»не хурлау белән мавыгалар [24, 130–131 б.].

Эшләү һәм яшәү шартлары бик авыр булуга карамастан, Н. Исәнбәт бу елларда иҗат эшен туктатмый. Дөнья әдәбиятын, бигрәк тә драматургиясен тирәнтен өйрәнүенә нигезләнеп, ул халыкчанлык юнәлешенә йөз белән борыла. Моны исә үзара кушылып китә ала торган ике концептуаль мәсьәлә белән бәйли. Берсе – тарихи шәхесләр һәм аларның җәмгыятьтәге урыны, икенчесе – халык авыз иҗатының бай мөмкинлекләреннән файдалану. Әдип драматургиясенең алдагы этабы буларак, «Спартак» (1932), «Миркәй белән Айсылу» (1935), «Хуҗа Насретдин» (1939), «Идегәй» (1941), «Җирән чичән белән Карачәч сылу» (1942), «Түләк» (1942) кебек әсәрләре языла һәм сәхнәгә менә. Беренчесеннән кала башкаларының бүген һәм киләчәктә дә сәхнә тотачагына шикләнмәскә мөмкин, чөнки аларда татар халкының гомерлек, буыннан буынга килә торган теләк-омтылышы – гадел җәмгыять төзү, кешеләр арасында тигезлеккә омтылу, кешенең бәхетле яшәешен иң зур кыйммәт буларак яклау чагыла. Әлеге төшенчәләр һәр әсәрдә, автор алга куйган концепциягә бәйле, төрле планда һәм сурәтләрдә чагылыш таба. «Нәкый Исәнбәт, фольклор комедиясе жанрында эшләп, фольклор әсәрләренең поэтик чынбарлыгын чорның актуаль мәсьәләләре белән бәйләргә омтыла. Тамашачы каршында тарих дөреслеген ачып, драматург заманның мөһим мәсьәләләрен хәл итүдә бабаларыбызның рухи байлыгы тәҗрибәсен күрсәтә» [10, 936]. «Миркәй белән Айсылу», «Хуҗа Насретдин», «Җирән чичән белән Карачәч сылу» да халыкның рухи дөньясы, азатлык хыялы, сугыш һәм тынычлык, мәхәббәт иреге, туганлык кадере, боларны яклап көрәшкә әзерлеге кебек җитди мәсьәләләр, урын һәм вакыт чиген үтеп чыккан кыйммәтләр буларак, киң планда гуманизмга хезмәт итә. Төп геройлар халыкның акылын, зирәклеген, җорлыгын чагылдыру ягыннан аеруча якын.

«Идегәй» трагедиясе Н. Исәнбәт иҗатында үзгә урын алып тора. Аның яңалыгы түбәндәгеләр белән аңлатыла: 1) автор ерактагы тарихка – татар тарихының гаять фаҗигале чорларына мөрәҗәгать итүе белән әдәбиятта читтә калып килгән мәсьәләгә килә: татар халкына үз тарихын кайтару бурычын алга куя; 2) совет чорында дөнья күргән тарихи әсәрләрдән аермалы буларак, вакыйга-күренешләрне ниндидер идеологик кысаларга бәйсез рәвештә ачу омтылышы ясый; 3) сәхнә әдәбиятына өр-яңа геройлар, тарихи шәхесләрнең әдәби образларын алып килә һәм аларны шул чор мохитенә бәйле бөтен каршылыклары белән ача. Бу яктан Идегәй образы – Н. Исәнбәтнең табышы, аның фаҗигасе тарихи шәхес һәм ил фаҗигасе буларак ачыла. Шәхси мәнфәгать һәм ил-халык өчен җаваплылык мәсьәләсе бу кадәр зур масштабта сурәтләнгәне булмый. Халык дастаныннан алынган герой тарих аша һәркемгә сабак бирә, милли үзаңны уята. Бу вакыйгадан соң инде татар әдипләре тарихи шәхесне сурәтләүгә килгәндә әлеге әсәргә салынган үзенчәлекләрне читләтеп үтә алмыйлар.

Бөек Ватан сугышы елларында Н. Исәнбәт алдагы чор эзләнүләрен дәвам итеп, яңа әдәби-эстетик юнәлешкә килә. Бу халыкның үз улларын һәм кызларын күрсәтү белән бәйле булып, әдип татар халкының иҗтимагый-мәдәни тормышына зур йогынты ясаган шәхесләрен сурәтләүгә алына. Язучыларның зур күпчелеге халыкны фашизмга каршы көрәшкә туплау, илне саклау, ант итү, геройлар үрнәгендә батырлыкка өндәү, фашизм ерткычлыгын ачу аша үч алырга, азатлык сугышына өндәү рухында иҗат итә. Әдип «Мәрьям» пьесасын язып, аның 1943 елны сәхнәгә куелуына ирешә. Бу яктан Н. Исәнбәтнең «Гөлҗамал» (1943), «Мулланур Вахитов» (1943–1944) драмаларына килүе гаҗәп тоелырга мөмкин. Әмма бу язучының туган җир азатлыгы, халык иреге, патриотизм мәсьәләләренә киңрәк каравын аңлата. Әлеге әсәрләре белән ул кеше рухының көче, үз-үзенә ышанычы, ныклык-батырлык чыганакларын, аның тамырларын эзләүгә килә. Н. Исәнбәт туган халкы язмышын Туган ил, Ватан төшенчәләре белән бербөтен итеп карый. «Гөлҗамал» драмасында сурәтләнгән XX йөз башы – татар халкының милләт буларак формалашу, уртак Ватанда үз урынын даулау чоры. Ә бу изге эшкә беренче хатын-кыз актриса Гөлҗамал (Сәхипҗамал Волжская) кебек бөек шәхесләр алына һәм башкарып чыга. Икенче әсәрдәге Мулланур Вахитов образы, идеологик йогынтыдан азат булмаса да, асылында халык азатлыгы өчен үзен корбан иткән, киң мәгънәдә гомумкешелек идеалларын яклаучы герой булып калка.

1944 елның 9 августында ВКП(б) Үзәк комитеты тарафыннан кабул ителгән «Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеологик эшләрнең торышы һәм аларны

яхшырту чаралары турында» дигән карарда татар халкының «Идегәй» дастанына «ханнар-феодаллар эпосы» дигән нахак гаеп ташлану татарның ерак тарихын өйрәнүгә киртә салган кебек, Н. Исәнбәтне дә гаять авыр хәлгә куя. Алдагы елларда дәреслекләрдә татар тарихы чагылышын тәнкыйтьләгән карарлар кабул ителү моны тагын да көчәйтә. Шундый шартларда Н. Исәнбәт иҗатында яңа этапка килә.

Фольклорга бәйле эзләнүләре, үткән тарихка һәм тарихи шәхесләргә нисбәтле иҗаты кискен тәнкыйтькә очраган әдип укучы-тамашачысы белән сәнгать әсәрләре аша аралашудан, караш-фикерләрен сурәт чаралары аша җиткерүдән тыелып кала алмый. Сугыштан соңгы еллардагы каршылыклы шартларда, «конфликтсызлык теориясе» өстенлек иткәндә ул совет җәмгыяте һәм кеше, беренче чиратта, хатын-кызларның урыны мәсьәләсен сурәтләүгә килә. «Рәйхан» (1948), «Гүзәл» (1950), «Зифа» (1954) кебек пьесалары бу чорда алгы планда торган әхлак һәм хезмәт мәсьәләләрен чагылдыра. Әдипнең әлеге пьесалары соцреализм кысаларыннан чыкмаса да, Н. Исәнбәт бөтен иҗатына хас булган үзенчәлеккә – татар хатын-кызын зурлауга, аның җәмгыятьтәге урынын үстерүгә тугры кала. Әдипнең Рәйхан, Гүзәл, Зифа кебек геройлары яңа тормыш, киләчәкнең матур җәмгыятен төзибез дип яшәүче самими, урыны белән беркатлы геройлар, шул ук вакытта алар татар хатын-кызларына хас матур сыйфатлары белән башкалардан аерылып торалар. Әлеге әсәрләрнең әһәмияте шунда: алар, бер яктан, репрессияләнгән әдипләр К. Тинчурин, Ш. Усманов, Ф. Борнаш һ.б. иҗаты әдәбият тарихыннан алып ташланган вакытта, актив иҗатта булган М. Әмир, Т. Гыйззәт, Г. Насрый һ.б. белән бергә, татар театрлары репертуарын саклап калуга, тамашачының театрга булган ихтыяҗын канәгатьләндерүгә хезмәт итә; икенче яктан, әлеге пьесалар Х. Вахит, А. Гыйләҗев, Ш. Хөсәнов, Т. Миңнуллинның 1960 елларда үсеп китәчәк лирик-психологик һәм социаль-психологик пьесаларына җирлек әзерлиләр.

Бу чорда Н. Исәнбәт әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан яңадан усал һәм урынсыз тәнкыйтькә дучар була. 1953 елны аның «Комедияләр һәм драмалар» [25] дигән сайланма пьесалар җыентыгы чыга. Андагы «Миркәй белән Айсылу» драмасы текстындагы «мәгърифәтче» һәм «җәдид» төшенчәләренең аңлатылуы зур шау-шу уята, хәтта китап җыентыкларын җыеп алу, юкка чыгаруга кадәр барып җитәләр. Бу турыда әдип болай дип яза: «...битенә корым ягылуга каршы бер мөгаллимәгә карата иске бер мулланың «син – җәдит мулла шәкерте» дигән бер җөмлә өчен, китабым басылгач, дөньяга чыкканчы конфисковать итеп яндырырга кушылды» [24, 140–141 б.].

Әдипне максатчан хезмәте генә бу ыгы-зыгыдан коткара. 1954 елны «язмыш тарафыннан зур сынау алдына куелган» [3, 226 б.] Муса Җәлил батырлыгына багышланган әсәр язуга алына. «Муса Җәлил» (1956) трагедиясе 1950 еллар татар драматургиясендәге сәнгати эзләнүләрнең бер казанышы булып тора. Язучының хатыны Гөлсем ханым истәлекләрендә болай ди: «Муса» трагедиясен язганда ул: «Мин “Муса” трагедиясен “шагыйрь һәм тиран” темасы итеп күрәм, шагыйрь – ирек, азатлык каһарманы, аны бер тиран да, зиндан да җиңә алмый, бу көрәштә һәрвакыт тиран җиңелә, шагыйрь авазы зиндан стеналары аша үтә, җыр һаман яши һәм тиранизмга нәфрәт булып яңгырый. Моның өчен миңа Мусаны Гитлер белән кара-каршы куярга кирәк. Ләкин, кызганычка, кулымда тарихи факт юк, аны Розенберг белән очраштырырга туры килә» [24, 449 б.], – дип сөйли иде. М. Җәлил батырлыгы тиңдәшсез булган кебек, аның әдәби образы да шуны таләп итә. Бу елларда М. Җәлил турында Р. Ишморат, Ш. Маннур, С. Хәким һ.б. әсәрләре дөнья күрә. Н. Исәнбәт беренчеләрдән булып мөрәҗәгать итә һәм аның трагедиясе фәлсәфи тирәнлеге, сугыш һәм тынычлык, үлем һәм үлемсезлек кебек мәңгелек темаларны гомумкешелек кыйммәтләре яссылыгында сурәтләве белән аерылып тора һәм үз вакытында югары бәяләнә. Җәлил татар улы, туган җирен, халкын яклап көрәшкә күтәрелгән солдат буларак сурәтләнә. Н. Ханзафаров язганча, «драматург иҗат максатын “шагыйрь һәм тиран көрәшен күрсәтү” дип билгеләсә дә, чынлыкта пьеса тагын да киңрәк колач ала. Ул заман проблемалары, халык язмышы, идеяләр көрәше турында әсәр булып үсә» [7, 158 б.].

Алдагы елларда Н.Исәнбәт үзен тулысынча фолькор һәм тел өлкәсендәге эзләнүләргә багышласа да, аның төрле елларда язылган «Кырлай егете» (1968), «Хәйләкәр Дәлилә, яки “Мең дә бер кичә”дән бер кичә» (1978) кебек әсәрләре тынгысыз җанлы әдипнең актив иҗатта булып, халыкның рухи мирасын

кайтару, саклау, яшь буынга җиткерү буенча эшчәнлеген күрсәтә.

## Төп нәтиҗәләр

Н. Исәнбәт сәхнә әдәбиятының драма, комедия, трагедия жанрларында уңышлы эшләп, һәрберсендә жанр формаларының яңа сыйфатларын ачуга, эчтәлек һәм форма бөтенлегенә ирешә (жанрның әсәр эчтәлегенә хас төп үзенчәлекләрне билгеләүче мөһим компонент булуын дәлилләүгә килә). Язучы әдәби үсешнең һәр этабында яңадан-яңа тема-мотивларга, гаять актуаль мәсьәләләргә мөрәҗәгать итә һәм еш кына татар сүз сәнгатенең үсеш юнәлешен, өстенле иҗат методын билгеләүгә ирешә. Ул XX йөз башы классиклары традицияләрен дәвам итә (милли яшәеш мәсьәләләрен үзәккә кую; гуманизм идеалларын яклау; карнавал көлү алымнарына мөрәҗәгать итү һ.б.) һәм әдәби барышка нисбәтле җитди яңалыклар алып килә (инкыйлаблардан соң «без» һәм «алар»га бүленгән татар җәмгыятендәге каршылыкларны эчтән торып ача, тышкы көлү аша «алар»ның фаҗигасен күрсәтә; 1920 елларда көчәеп киткән советчыл мифларны фаш итеп, совет җәмгыятендә урнашкан җитди кимчелекләрдән ачы көлә; сугыш елларында патриотизмның үз-үзеңне танып белү һәм милли үзаң белән тыгыз бәйләнештә булуын тарихи эчтәлекле пьесаларында раслый; сугыштан соңгы елларда үз йөзе белән аерылып торган хатын-кыз геройлары һәм төрле жанр сыйфатларының бер әсәрдә урын алуы белән яңа эчтәлеккә ирешү аша конфликтсызлык теориясен үтеп чыгуга җирлек тудыра һ. б.). Киң катлам укучы-тамашачыда яклау тапкан пьесалары шәхеснең үз-үзен танып белүенә, туган җиргә, телгә, халыкка хөрмәт һәм горурлык хисе формалаштыруга, тәрбияләүгә хезмәт итә. Н. Исәнбәт пьесаларында татар тарихының төрле чорлары чагылыш табып, автор аларны үзе яшәгән дәвер, аның җитди мәсьәләләре белән тыгыз бәйләнештә ачуга килә. Әдипнең күпсанлы әсәрләре бербөтен буларак каралып, аларда татар халкының тулы яшәеш картинасы күз алдына бастырыла. Пьесалары сюжет-композиция ачыклыгы белән аерылып тора һәм көнкүреш вакыйгалары аша чор үзенчәлеген, яшәешнең җитди мәсьәләләрен тыгыз бәйләнештә ачуга килә. Н. Исәнбәтнең һәр пьесасында автор образы үзгә урын алып, ул эчке һәм тышкы каршылыкларда, аларның чишелешендә чагылыш таба.

## Йомгаклау

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: Н. Исәнбәтнең татар сәхнә әдәбиятында алыштыргысыз урыны бар, ул эчтәлек һәм формага бәйле яңа традицияләргә нигез сала, ә инде «Һиҗрәт», «Портфель», «Хуҗа Насретдин», «Миркәй белән Айсылу», «Идегәй», «Гөлҗамал», «Муса Җәлил» кебек пьесаларының, заман сынавын үтеп, бүген дә театр сәхнәләренә менүе, әдип иҗатының заманчалыгы турында сөйли. Шуның белән бергә, Н. Исәнбәт драматургиясен өйрәнүне дәвам итеп, ул түбәндәге бурычларга нисбәтле эзләнүләр сорала: әсәрләрен, совет чорында урын алган стереотиплардан арынып, бөтен тулылыгында һәм объектив бәяләү; пьесаларның язылу тарихын, моңа китергән шартларны ачыклау һәм әдәби процесс белән тыгыз бәйлелектә шәрехләү; текстларның икенче катламында ачылган уй-фикерләрне ачу; поэтик үзенчәлекләрен Идел-Урал буе халыклары әдәбиятларында барган эзләнүләр белән чагыштырма планда өйрәнү.

**Әдәбият**


1. *Урманче Б.* Исәнбәтнең урыны // Казан утлары. 1969. № 12. Б. 134–136.
2. *Ахмадуллин А. Г.* Татарская драматургия: история и проблемы. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. 511 с.
3. *Әхмәдуллин А. Г.* Жанрлар һәм характерлар остасы // Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. Б. 220–228.
4. *Әхмәдуллин А. Г.* Гасырны үзенә сыйдырган иҗат // Офыклар киңәйгәндә. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. Б. 175–179.
5. *Рахмани Р., Миңнуллина Ф.* Нәкый Исәнбәт // Татар әдәбияты тарихы: 8 т.: 5 т. : 1917–1956 еллар / [фәнни мөх. Д. Ф. Заһидуллина]. – Яңарт. һәм тулыл. 2 нче басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2024. Б. 340–360.
6. *Миннуллина Ф. Х.* Н. Исәнбәт иҗатында шәхес иреге // Фәнни Татарстан. 2017. №4. Б. 62–67.
7. *Ханзафаров Н.* Нәкый Исәнбәт драматургиясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 191 б.
8. *Арсланов Г.* Фольклорный театр Наки Исанбета // Гасырлар авазы. Эхо веков. 2012. №1–2. С. 251–254.
9. *Арсланов М. Г.* «Муса Джалиль» Н. Исанбета: реконструкция, сценическая история первой постановки: [о спектакле «Муса Джалиль» Н. Исанбета, поставленный в ТГАТе им. Г. Камала режиссером П. Исанбетом в 1957 г.] // Вестник

Казанского государственного университета культуры и искусств. 2018. № 4. С. 85–91.

10. *Замалетдинов Р., Хабутдинова М.* Творческая история комедии Наки Исанбета «Рыжий чичян и Черноволосая красавица» // Золотоордынское обозрение. 2023. Vol.11, Is.4. С. 934–956.

11. *Шамуков Г.* Нәкый Исәнбәт: монография. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. 76 б.

12. *Хабутдинов А. Ю., Хабутдинова М. М.* Историческая основа и прототипы героев пьесы Н. Исанбет «Һиҗрәт» (1923): размышления после спектакля «Качаклар» («Беглецы») (режиссер И. Зайниев)// Tatarica. 2017. №1 (8). С. 107–123.

13. *Хабутдинова М. М.* Образ Наки Исанбета-педагога в воспоминаниях его учеников // Russian Linguistic Bulletin. 2022. №4 (32). С. 1–7.

14. *Хабутдинова М. М.* Творческая история пьесы «Гөлҗамал» («Гульжамал») в зеркале переписки Н. Исанбета с С. Гиззатуллиной-Волжской // Филология и культура. Philologie and Culture. 2022. №3(69). С. 180–187.

15. *Хабутдинова М. М.* Роль и место татарской женщины в творчестве Наки Исанбета // Историческая этнология. 2024. Т.9. № 1. С. 38–48.

16. *Хабутдинова М. М.* Медиаобраз Наки Исанбета в аспекте интерпретации его творчества // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2022. Том 15. Выпуск 7. С. 2119–2123.

17. *Батулла Р.* Үз Насретдиныбыз // Идел. 1999. № 12. Б. 30–40.

18. *Батулла Р.* Әдип белән очрашуларым (Нәкый Исәнбәтнең тууына 120 ел) // Мәдәни җомга. 2020. 31 гыйнвар.

19. *Госманов М.* Аксакаллар мәҗлесеннән (Нәкый Исәнбәт турында истәлекләр) // Казан утлары. 2010. № 11. Б. 121–135.

20. *Еники Ә.* Нәкый Исәнбәт // Хәтердәге төеннәр: мәкаләләр, очерклар һәм истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 3–7 б.

21. *Хәбетдинова М.М.* «Чорлар рухание» // Казан утлары. 2020. №1. Б. 150–162.

22. Хабутдинова М. М. Вклад Наки Исанбета в изучение Золотой Орды // Золотоордынское обозрение. 2023. Т. 11, №1. С. 181–201. DOI: 10.22378 /2313-6197.2023-11-1.181-201 EDN: NZKGGK

23. *Фәйзуллин Р.* Син сазыңны уйнадың // Илбагар уйлар, фәлсәфи язмалар, әдәби портретлар, хатирә-уйланулар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 294–295.

24. Нәкый Исәнбәт: фәнни-популяр җыентык / Төз. М. М. Хәбетдинова. Казан: Җыен, 2021. 736 б.

25. *Исәнбәт Н.* Комедияләр һәм драмалар. Казан: Татгосиздат, 1953. 449 б.

# НАКИ ИСАНБЕТ И ТАТАРСКАЯ ДРАМАТУРГИЯ

**Альфат Магсумзянович Закирзянов**,
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан,
Россия, 420111, г. Казань, ул. Карла Маркса, д. 12,
Alfat_zak@mail.ru.

В статье очерчен вклад татарского ученого, поэта, драматурга, фольклориста, переводчика, публициста Наки Исанбета в развитие татарской драматургии. На этом поприще просветитель активно и результативно трудился в 1910–1970-е гг. Его перу принадлежит свыше 30 пьес, которые были поставлены на сцене. Писатель отразил в своих произведениях важные события, значимые страницы истории, поэтому они воспринимаются летописью татарской жизни. В статье кратко охарактеризованы этапы творчества Наки Исанбета, выявлены особенности каждого из них. Как писатель-драматург он снискал славу еще в 1920-е гг. В пьесах революционной поры доминируют социальные конфликты, высмеиваются баи и религиозные деятели, потерявшие почву под ногами. В дальнейшем Наки Исанбет совершает крутой поворот: драматург создает пьесы на фольклорной основе, посвященные историческим деятелям татарского народа. Тематика и проблематика его произведений отличается новизной. Наки Исанбет вывел на сцену новые типы. Это дало основание критикам заговорить о феномене «Театр Наки Исанбета».

**Ключевые слова**: татарская драматургия, Наки Исанбет, этапы творчества, литературный процесс, традиции и новаторство, герои эпохи, своеобразие конфликта

**Для цитирования**: Закирзянов А.М. Наки Исанбет и татарская драматургия // Tatarica. 2025. № 1 (24). pp. 34–48. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-24-1-34-48